КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 21 сентябрь г.Казань № 820

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен күтәрү турында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәте өчен түләүне җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 20 июнь, 497 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1287 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы; 2022 ел, 2 август, 751 нче; 2022 ел, 27 август, 916 нчы; 2022 ел, 17 сентябрь, 1013 нче, 2024 ел, 29 апрель, 287 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2025 елның 1 гыйн-варыннан арттырырга.

2. Бу карарның 1 пункты нигезендә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләү өчен муниципаль берәмлекләрдә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмасындагы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладының күләмен 1,05 тапкырга индексацияләргә һәм аның күләмен 13 990 сум күләмендә билгеләргә.

3. Кайбер оешмалар җитәкчеләренә элегрәк чыгарылган актларын бу карарга туры китерергә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин